ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 ноябрь, 2016 ел № 11/8

Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү мәсьәләләре турында

Шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. «Шәһәр муниципаль учреждениеләрен җитештерү-техник тәэмин итү үзәге» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном учреждениесендә (алга таба – учреждение) хезмәткә түләү түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырыла:

1) учреждение җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары, белгечләре, хезмәткәрләре өчен – Шәһәр Советының 2010 елның 26 маендагы 50/5 санлы Карары белән расланган Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү тәртибе һәм шартлары турында нигезнамәнең 10 бүлеге нигезендә;

2) учреждение эшчеләре өчен – Шәһәр Советының 15 апрелендәге 39/8 санлы Карары белән расланган Муниципаль учреждениеләр эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һәм җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификацион төркемнәре хезмәткәрләренә түләү шартлары турында нигезнамәгә таянып.

2. Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге «Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү өлкәсендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 9/8 санлы Карары көче 2016 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 25 ноябрендәге 889 санлы, 2016 елның 26 гыйнварендәге 38 санлы, 2016 елның 13 маендагы 314 санлы, 2016 елның 27 июнендәге 438 санлы карарлары белән үз көченә керүнең башка вакыты каралган нигезләмәләрдән тыш.

3. Шәһәр Советының 2016 елның 8 июлендәге «Аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре хезмәтләренә түләү

өлкәсендә Шәһәр Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 9/8 санлы Карарының 5, 6 пунктлары үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев